**ГЛАВА НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА И ГОРОДА НУРЛАТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҺӘМ НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 114 «23 » сентябрь 2024 ел

Җир кишәрлекләреннән шартлы рәвештә файдалануның рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча Нурлат шәһәрендә гавами тыңлаулар билгеләү турында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 23 мартындагы 53 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддәсе, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Кызыксынган затларга җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә:

1.1. Габдрахманова Мәйсәрә Галимҗан кызына түбәндәге адрес буенча урнашкан 16:56:010195:183 кадастр номерлы, 910 кв. м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәтләр: ТР, Нурлат муниципаль районы, Нурлат шәһәре, Сиреневая ур., 10 – «Блоклы торак төзелеше»;

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручы итеп Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген билгеләргә..

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 07.10.2024, 14:00 сәг.;

3.2. үткәрү срогы-әлеге карар басылып чыккан көннән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан артыграк түгел;

3.3. үткәрү урыны-ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының кече залы, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: ТР, Нурлат ш., Совет ур., 117 йорт.

3.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган, гавами тыңлауларда катнашуга чыгыш ясау хокукы белән гаризалар бирелә торган адрес: Нурлат шәһәре, Совет урамы, 117 йорт (архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге);

3.5. чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты – 01.10.2024 елга кадәр. (тел.3-19-09).

4. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә халык тыңлавына чыгарыла торган мәсьәлә буенча экспозиция оештырырга, физик һәм юридик затлардан тәкъдимнәр, тәкъдимнәр һәм гаризалар кабул итәргә: Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Совет ур., 117 йорт.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Д.А. Ишкинеев